Республика Татарстан Кукморский муниципальный район Совет
Байлянгарского сельского поселения
422121, с.Байлянгар, ул. Советская,6
Тел./факс (8 84364) 34-7-39,
e-mail:Bay.Kuk@tatar.ru

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы
Байлангар авыл Җирлеге Советы
422121, с.Байлянгар, ул. Советская,6
Тел./факс (8 84364) 34-7-39,
e-mail:Bay.Kuk@tatar.ru

# РЕШЕНИЕ

«16» июнь 2025 ел № 15

Байлангар авыл җирлеге Советының 2018 елның 05 июнендәге 11 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Байлангар авыл җирлегенең вәкаләтләрне даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Муниципаль хезмәт турында 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Кодексы, «Татарстан Республикасында үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларга, җирле үзидарәнең сайлап куелган вазыйфаи затларына, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренә, рәис урынбасарларына, аудиторларга, муниципаль хезмәткәрләргә хезмәт хакы түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына үзгәрешләр кертү турында» 2025 елның 14 апрелендәге 228 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә Байлангар авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. Байлангар авыл җирлеге Советының 2018 елның 05 июнендәге 11 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Байлангар авыл җирлегенең вәкаләтләрне даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәгә (алга таба – Нигезләмә), Байлангар авыл җирлеге Советының 2018 елның 07 нояберендәге 26 номерлы 2020 елның 21

декабрендәге 14 номерлы, 2022 елның 29 декабрендәге 42 номерлы, 2024 елның 11 июнендәге 16 номерлы, 2024 елның 13 августындагы 22 номерлы, 2024 елның 03 декабрендәге 37 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып, түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) 2.1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.1. Муниципаль берәмлек башлыгына айлык акчалата түләү түбәндәгедән артмаган күләмнәрдә билгеләнә:

| Вазыйфаның исеме | Айлык акчалата түләүнең күләме (сумнарда) |
|---|---|
| | Уникенче төркем (халык саны 1,5 мең кешегә кадәр) |
| Муниципаль берәмлек башлыгы | 21 091,0 |

б) 2.4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.4. Айлык акчалата түләү 12 төркемгә кертелгән муниципаль берәмлек башлыгы өчен нормативтан артмаган күләмдә түләнә – елына 15,48 айлык акчалата түләү.»;

в) 3.1 пунктның беренче абзацында «13990» санын «15389» санына алмаштырырга.

г) 3.5 пунктында «41 процент» сүзләрен «58 процент» сүзләренә алмаштырырга;

д) 4 бүлекнең 1 пунктындагы 6 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6) айлык акчалата түләү – хезмәт окладына карата 58 проценттан артмаган күләмдә.»

2. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2025 елның 1 маеннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

Байлангар авыл җирлеге башлыгы И.Ф.Каримуллин